Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Пестречинского
муниципального района
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль
районы
башкарма комитеты
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«16» декабрь, 2025 ел № 954-п

Күпфатирлы йорт белән идарә итү өчен идарәче оешманы сайлап алу буенча ачык конкурс үткәрү тәртибе турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 161 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йорт белән идарә итү өчен идарәче оешманы сайлау буенча ачык конкурс уздыру тәртибе турында» 2006 елның 6 февралендәге 75 номерлы карарын үтәү өчен Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда Питрәч муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йорт белән идарә итү өчен идарәче оешма сайлап алу буенча ачык конкурс үткәрергә;

2. Күпфатирлы йорт милекчесе белән күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсе проектын расларга (1 нче кушымта);

3. конкурс комиссиясе төзергә һәм аның составын расларга (2 нче кушымта);

4. Күпфатирлы йорт белән идарә итү өчен идарәче оешманы сайлап алу буенча конкурс комиссиясе эше тәртибен расларга (3 нче кушымта);

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (http://pestreci.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Җитәкче И.Р. Дәүләтханов